| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| Совет | Түбән Кама муниципаль районы |
| Нижнеуратьминского сельского поселения | Түбән Уратма авыл жирлеге |
| Нижнекамского муниципального района | Советы |
| 423567, Нижнекамский район, | 423567, Түбән Кама районы, |
| с. Нижняя Уратьма ул. Центральная, 1 | Түбән Уратма авылы, Үзәк урамы, 1 |

тел./факс (8555) 33-17-25, электронный адрес: Nizhneuratminskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.nizhneuratminskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

07.03.2023 ел № 7

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмалар булдыру, аларны карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 04 февралендәге 5 номерлы Түбән Уратма авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Уратма авыл җирлеге Советы карар бирә:

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмалар булдыру, аларны карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 04 февралендәге 5 номерлы Түбән Уратма җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

10 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Яшел утыртмаларны алу гариза бирүче тарафыннан тикшерү акты нигезендә, алып ташлана торган яшел утыртмалар бәясен исәпләүнең расланган методикасы буенча исәпләнгән экологик зыян күләмендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге территориясендә компенсацияле яшелләндерү үткәрү акчалата яисә табигый рәвештә компенсацияле (торгызу) яшелләндерү башкару юлы белән компенсацияләнә.

Акчалата компенсация гариза бирүче тарафыннан яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт бирелгәнче башкарыла.

Натураль төрдәге компенсация гариза бирүче тарафыннан яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт бирелгән көннән бер ай эчендә башкарыла. Гамәлдәге елның 15 октябреннән соң яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт биргәндә, натураль төрдәге компенсация киләсе елның 15 апреленнән бер ай эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат такталарында, шулай ук Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Р.Гарифуллин